
«Тел- милләтнең язмышы, аның сакчысы»
Ә.Кәримуллин

# ТАТАР ТЕЛЕ ДӘРЕСЛӘРЕНДӘ КОМПЕТЕНЦИЯ ТӘРБИЯЛӘҮГӘ ЮНӘЛТЕЛГӘН БИРЕМНӘР (ИСЕМ СҮЗ ТӨРКЕМЕН ӨЙРӘТҮ МИСАЛЫНДА)



**Башкардылар:**
**Шакирова Гөлназ Малик кызы,**
**Гарифуллина Илһамия Рәис кызы**



elenaranko.ucoz.ru

**Максат** – татар теле дәресләрендә компетенция тәрбияләүнең әһәмиятен күрсәтү.

**Бурычлар**:

- компетенция төшенчәсенең фәнни-методик әдәбиятта бирелешен ачыклау;
- компетенция тәрбияләүгә юнәлтелгән биремнәрнең асылы, төзелеше һәм эчтәлеге турында мәгълүмат бирү;
- исем сүз төркемен үткәндә куллану өчен коммуникатив, лингвистик, этномәдәни компетенция тәрбияләүгә юнәлтелгән биремнәр төзү.



elenaranko.ucoz.ru

# Көтелгән нәтиҗәләр

- Компетенция тәрбияләүгә юнәлтелгән биремнәр татар теле дәресләрен нәтиҗәле һәм мавыктыргыч итәчәк.
- Алар ярдәмендә укучылар тел материалын тизрәк һәм яхшырак үзләштерәчәк.
- Кайбер биремнәр сөйләү кимчелекләрен бетерергә, милләтара дуслыкны ныгытырга, гореф-гадәтләрне сакларга ярдәм итәчәк.

elenaranko.ucoz.ru

# Коммуникатив компетенция

Яшь үзенчәлекләрен, укучының тоткан статусын, әңгәмәдәшнең үзенчәлеген исәпкә алып иптәшлеге, танышлыгы ягыннан төрле әңгәмәдәш белән контактка керә белү. Аралашуның кагыйдәләрен һәм нормаларын бозмыйча, невербаль (кул хәрәкәтләре, мимика) чаралар кулланып, монологик һәм диалогик формаларда аралаша белү.

elenaranko.ucoz.ru

# Лингвистик компетенция

Тел система һәм иҗтимагый-мәдәни күренеш буларак өйрәнелә. Татар теленең барлык бүлекләре буенча үзләштерергә тиешле төп теоретик мәгълүматлар карала.

elenaranko.ucoz.ru

# Этномәдәни компетенция

- Өйрәнелә торган телдә сөйләшүче халыкның, безнең очракта татар халкының, милли-мәдәни үзенчәлекләре белән танышып, тел нормаларын истә тотып, шул милләт кешесе белән уңышлы аралаша алу.
- Телне үзләштерү барышында халыкның мирасын өйрәнү.
- Телне саклау һәм үстерү.

elenaranko.ucoz.ru




elenaranko.ucoz.ru

| Укытучы | Исламова Миләүшә Юныс кызы |
|---|---|
| **Сыйныф, тема** | 6 нчы сыйныф, “Исемнәрне кабатлау” |
| **Компетенция** | Лингвистик, коммуникатив |
| **Стимул** | Синең дустың озак авырды һәм бик күп дәресләр калдырды. Синең калдырылган дәресләрне аңлатырга мөмкинлегең бар. |
| **Формулировка** | Исемнәргә хас үзенчәлекләрне барлап, таблицага язарга |
| **Чыганак** | 1.Исем сүз төркеме предметны белдереп, кем? нәрсә? сорауларына җавап бирә.<br>2.Ялгызлык һәм уртаклык исемнәр була.<br>3.Исемнәр килеш, тартым, сан белән төрләнә.<br>**Исемгә хас билгеләр:**<br>а) килеш<br>б) күплек сан<br>в) ялгызлык исемнәр<br>г) тартым белән төрләнү |

elenaranko.ucoz.ru

# Җавапларны тутыру өчен бланк

| № | Биремнәр | Җавап | Балл |
|---|---|---|---|
| 1 | Ике яки берничә предметны белдерә торган исемнәр | | 1 |
| 2 | Төрдәш предметларның берсенә генә бирелә торган исемнәр | | 1 |
| 3 | Предметларның нинди дә булса затка караганлыгын белдергән исемнәр | | 1 |
| 4 | Җөмлә кисәкләре белән бәйләнешкә кергәндә исемнәр нәрсә белән төрләнә. | | 1 |

elenaranko.ucoz.ru

# Бәяләү инструменты (җавап моделе)

| № | Биремнәр | Җавап | Балл |
|---|---|---|---|
| 1 | Ике яки берничә предметны белдерә торган исемнәр | б | 1 |
| 2 | Төрдәш предметларның берсенә генә бирелә торган исемнәр | в | 1 |
| 3 | Предметларның нинди дә булса затка караганлыгын белдергән исемнәр | г | 1 |
| 4 | Җөмлә кисәкләре белән бәйләнешкә кергәндә исемнәр нәрсә белән төрләнә. | а | 1 |

«5» - 4 балл
«4» - 3 балл
«3» - 2 балл

elenaranko.ucoz.ru



1.Рәсемгә карап, исем сүз төркеменә кергән сүзләрне санарга.

Сүзләрне килеш, тартым һәм сан белән төрләндереп әйтергә.

2. Рәсемгә нинди халык мәкальләре туры килә?

3. Җыр атамасына ялгызлык исемнәре кергән халык җырларын санарга.

elenaranko.ucoz.ru

**Шулай итеп,** балаларга исем темасын өйрәткәндә компетенция төрләрен кулланып, уңай нәтиҗәләргә ирешергә мөмкин. Компетенция формалаштыру юлларын дөрес оештырганда, ул укучыларның тел өйрәнүгә карата мөнәсәбәтләрен уңай якка үзгәртә, белемнәрнең аңлылыгына этәрә, мөстәкыйльлеккә өйрәтә, иҗади фикерләүне үстерә. Бары тик оста оештырылган дәресләр генә балаларга телгә карата кызыксыну уята ала.

elenaranko.ucoz.ru

# Игътибарыгыз өчен рәхмәт!

elenaranko.ucoz.ru